# 2-3 яшлек балаларның иҗади сәләтләрен рәсем эшчәнлегендә гадәти булмаган ысуллар куллану ярдәмендә үстерү

Төзеде: 74нче балалар бакчасы тәрбияче
Вәлиева Әлфия
Вәлиҗан кызы

DESIGN-WAREZ.RU

# Рәсем ясау-ул хыяллану, ләкин кәгазьдә генә





Бакчабызда бик күңелле,
Кояш балкый безнең йөздә.
Шатланышып киләбез без,
“Карлыгач”та рәхәт безгә.

Тәрбияче апаларның
Кояш кунган йөзләренә.
Алар безгә әни кебек,
Утырабыз тезләренә.

Уйныйбыз да, җырлыйбыз да,
Спортта да сынатмыйбыз.
“Карлыгач”та рәхәт безгә,
Без беркайчан тик ятмыйбыз.

Әнә шундый бик күңелле
Бакчабыз бар, белегез сез.
Аны күрәсегез килсә
Бер кунакка килегез сез!

# Гадәти булмаган алымнар куллану балаларның төрле яктан үстерә:



- логик фикерләвен;
- күзәтчәнлеген;
- игътибарын ;
- үз-үзенә ышанычын арттыра;
- балалар төсләрне аера белергә өйрәнәләр;
- диалогик һәм монологик сөйләмнәре үсә;
- балаларның фантазияларын арттырып җибәрә;
- күңел күтәренкелеге арта;
- вак моторикасын  үстерә.







Гадәти булмаган алымнар
оттиск
Бармак очы һәм уч төбе белән рәсем ясау
Комда рәсем ясау
Шәм + акварель
Монотипия
Фроттаж
Кляксография
Пластилинография
Үпкә ярьдәмендә (сабын куыклары кабартп)
Набрызг
Граттаж
Мамык таяк-чыклары белән рәсем ясау
Бөгәрләнгән кәгазъ белән рәсем ясау
Ярмада рәсем ясау
Печать техникасы
штамп

# Комда һәм ярмада рәсем ясау

**Рәсемнәр ясыйбыз**

*Бари Рәхмәт*

Бакчада барысы бар!
Тик менә юк таулар,
Елгалар, урманнар,
Зур йортлар, урамнар.
Ә кирәк булганда
Ясыйбыз урамнар,
Ямь-яшел урманнар,







## Бармак очы
## белән рәсем ясау

## Мамык таякчыклары белән рәсем ясау



Яфракларны күр әле
Алтын төскә кергәннәр.
Бар дөньяны күмгәннәр.
Җил чыкканда шаулашалар,
Оча-оча уйнашалар,
Һавада әйләнәләр
Һәм жиргә сибеләләр







# Мамык таякчыклары белән рәсем ясау

**Карны кем ясый?**
**(Зиннурова Ф.М.)**

**Кар яуганны карап тордым**
**Тәрәзәдән беркөнне.**
**Ап-ак үзе, бизәкләре**
**Йолдыз кебек, күр инде.**

**Кем соң аны ясый икән,**
**Кем сибеп тора икән?**
**Ничек куллары туңмый да,**
**Каян кар җитә икән?**





# <u>Уч төбе белән рәсем ясау</u>








# Паралон һәм трафарет белән рәсем ясау

**Төлкеләр, куяннар...**
**Бик оста без аңар,**
**Бездә бар буяулар:**
**Ак, кызыл, ал, зәңгәр,**
**Сарылар, яшелләр...**
**Ясыйбыз дәфтәргә**
**Бик матур рәсемнәр.**





# Яфрак һәм шакмак белән

Менә көз килде.
Салкынча, җилле.
Агачларда яфраклар
Саргайды инде.







# “Сыерчыклар шәһәрчеге”- бәрәнге белән

**Сыерчык**

**Өй түрендә – бакчада,**
**Талчыбык куначада**
**Сыерчык канат кага –**
**Яз килүгә шатлана.**
**Җилпенә ул, талпына,**
**Шатланып сайрап куя.**
**Ак каенның башында**
**Бик матур оя тора.**
**Чут-чут итеп сайравы-**
**Аның оя сайлавы**
**Кем ясаган ояны-**
**Сыерчык белә аны.**

**Гасыйм Лотфи**







# Каты пумала (тычок)

Салкын, саф һава
*Әминә Бикчәнтәева*
Салкын, саф һава,
Йомшак кар ява.
Урамга чыксаң,
Битләр кызара.

Кар бөртекләре
Өстеңә куна,
Үзләре матур
Һәм салкын була.





# Бөгәрләнгән кәгазъ белән рәсем ясау

Ул өстенә җәй дә, кыш та.
Энәле күлмәк кия,
Шулай да аны әнкәсе
“Йомшагым “диеп сөя. (керпе)





# Пластилин штампы белән рәсем ясау

Ак чәчәкләр, күк чәчәкләр
Күп чәчәкләр аланда
Без исемен белми торган
Чәчәкләр дә бар анда.





***Гади эшнен нәтиҗәсе***
***Сихри бер зур ачыш***
***Илһам килеп эшләнгән эш-***
***Гаҗәп гүзәл күренеш***

# ИГЪТИБАРЫГЫЗ ӨЧЕН РӘХМӘТ!